ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01.11.2019 Баулы шәһәре № 306

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 12 февралендәге 31 номерлы карары белән расланган Баулы муниципаль районы территориясендә җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутларында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга киткән чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында транспорт йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

"Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш), индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товар, эшләр җитештерүче, хезмәт күрсәтүче физик затларга субсидияләр бирүне җайга салучы муниципаль хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 12 сентябрендәге 1187 номерлы Карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 12 февралендәге 31 номерлы карары белән расланган Баулы муниципаль районы территориясендә җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутларында халыкка транспорт

хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга киткән чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында транспорт йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктының сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

" - субсидия алучылар - юридик затлар үзгәртеп кору, бетерү процессында булырга тиеш түгел, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә субсидия алучылар -индивидуаль эшкуарлар эшчәнлеген индивидуаль эшкуар буларак туктатмаска тиеш;».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров